Апаз авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе

07 июнь 2019 ел Апаз авылы 14 сәг.00 мин.

Үткәрү урыны: Апаз авылы, Совет урамы, 18, Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты
Катнаштылар 30 кеше
Барлыгы 30 кеше

Гарифуллин Рафаэль Мөдәрис улы: Хәерле көн, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгының 2019 елның 26 мартындагы 1 номерлы карары нигезендә, бүген бездә Апаз авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрелә. Гавами тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы итеп җирлек башлыгы – Садиков Ренат Шамил улы билгеләнде.

Секретарь: Котдусов Раушан Фарадис улы — авыл җирлекләренең хокук мәсьәләләре буенча белгече.

Апаз авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 30-34 ст., "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль нигезендә башкарылды.

Апаз авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар датасы, карарлар проекты турында мәгълүмат Татарстан Республикасы рәсми мәгълүмат порталында, түбәндәге адреслар буенча авыл җирлеге стендларында урнаштырылды: ТР, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 18; ТР, Арча районы, Хәсәншәех авылы,. Космонавтлар урамы, 20 , ТР, Арча районы, Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А,; ТР, Арча районы, Мирҗәм авылы, Н.Сафин урамы, 36.

Апаз авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар ТР, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 18 адресы буенча үткәрелә. Гавами тыңлаулар үткәргәнче, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең ПЗЗ проекты буенча язма кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кермәде. 2019 елның 06 апреленнән 06 июненә кадәр Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең ПЗЗ проекты буенча язма һәм телдән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү срогында шулай ук бернинди искәрмәләр дә, тәкъдимнәр дә кермәде.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре муниципаль берәмлекләр территорияләрен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелешен зоналаштыруга карый. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү яңа Генераль планны раслауга, РФ Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертүгә бәйле.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре үз эченә ала: аларны куллану һәм әлеге кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе; шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы; шәһәр төзелеше регламентлары.

Гарифуллин Рафаэль Мөдәрис улы: Сораулар бармы? Гавами тыңлаулар үткәрү барышында кисәтүләр булмады, кергән тәкъдим игътибарга алыначак. Әгәр дә сораулар булмаса, гавами тыңлаулар үтте.

Гавами тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы Садиков Ренат Шамил улы
Секретарь Котдусов Раушан Фарадис улы